КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 19 сентябрь г.Казань № 714

Мәгариф өлкәсендә психологик-педагогик, коррекцион-үстерү, компенсацияләү һәм педагогик ярдәм күрсәтү буенча дәүләт хезмәтләре сыйфаты стандартларын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Укучыларны, аларның ата-аналарын (законлы вәкилләрен), педагогик хезмәткәрләрне психологик-педагогик консультацияләү буенча дәүләт хезмәте сыйфаты стандарты;

Укучыларга коррекцион-үстерү, компенсацияләү һәм логопед ярдәме күрсәтү буенча дәүләт хезмәте сыйфаты стандарты.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Укучыларны, аларның ата-аналарын (законлы вәкилләрен), педагогик хезмәткәрләрне психологик-педагогик консультацияләү буенча дәүләт хезмәте сыйфаты стандарты һәм Балигъ булмаган укучыларга коррекцион-үстерү, компенсацияләү һәм логопед ярдәме күрсәтү буенча дәүләт хезмәте сыйфаты стандарты раслау турында» 2020 ел, 1 июнь, 450 нче карары үз көчен югалтуын танырга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 19 сентябрь , 714 нче
карары белән расланды

## Укучыларга коррекцион-үстерү, компенсацияләү һәм логопед ярдәме күрсәтү буенча дәүләт хезмәте сыйфаты стандарты

### I. Дәүләт хезмәтен алучылар категорияләре

1.1. Коррекцион-үстерeш, компенсацияләү һәм логопедик ярдәм күрсәтү буенча дәүләт хезмәтен алучылар (алга таба – дәүләт хезмәте) мәктәпкәчә белем бирү, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм (яки) урта гомуми белем бирү, урта һөнәри белем бирү һәм (яки) төп һөнәри укыту программаларын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларында укучылар, шул исәптән инвалид балалар (алга таба – укучылар) булып торалар.

### II. Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең хокукый нигезе

2.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне көйләүче норматив хокукый актлар:

1989 елның 20 ноябрендә Берләшкән Милләтләр Оешмасының Генераль Ассамблеясе тарафыннан расланган Бала хокуклары турында конвенция;

Россия Федерациясе Конституциясе;

Россия Федерациясе Гаилә кодексы;

«Кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законы;

«Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» 1998 елның 24 июлендәге 124-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон;

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Педагог-психолог (мәгариф өлкәсендә психолог) һөнәри стандартын раслау турында» 2015 елның 24 июлендәге 514н номерлы боерыгы;

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Педагог-дефектолог һөнәри стандартын раслау турында» 2023 елның 13 мартындагы 136н номерлы боерыгы;

Татарстан Республикасы Конституциясе;

Татарстан Республикасы Гаилә кодексы;

«Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре сыйфатының стандартлары турында» 2009 ел, 30 июнь, 445 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре күрсәтә торган дәүләт хезмәтләре фактта күрсәтелә торган

дәүләт хезмәтләре сыйфатының билгеләнгән стандартларына туры килүен бәяләүне уздыру тәртибе турында» 2009 ел, 30 июнь, 446 нчы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы мәгариф оешмаларында уку һәм тәрбия бирү чорында балигъ булмаганнарга беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтү шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» 2017 ел, 7 декабрь, 952 нче карары;

әлеге Стандарт;

Россия Федерациясендә мәгариф өлкәсендә психологик-педагогик ярдәм системасын үстерү концепцияләре;

дәүләт хезмәтен күрсәтүче оешманың уставы, локаль актлары.

2.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон белән көйләнми.».

## III. Дәүләт хезмәтен алу өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

3.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен дәүләт хезмәтен күрсәтү турында килешү төзелә.

3.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында килешү түбәндәге документлар нигезендә төзелә:

| Т/с | Документлар исемлеге | Документны бирүче оешма яки документны бирү өчен җаваплы затлар | Документның гамәлдә булу срогы |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Россия Федерациясе гражданнары өчен | | | |
| 1. | Укучының шәхесен раслый торган документ:<br>туу турында таныклык (14 яшькә кадәр);<br>Россия Федерациясе гражданины паспорты (14 яшьтән һәм өлкәнрәк) | граждан хәле актларын теркәү органнары;<br>Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының территориаль органнары | 14 яшькә кадәр;<br>законнар нигезендә |
| 2. | Укучы мәнфәгатьләрендә дәүләт хезмәте күрсәтү турында килешү төзүче укучының әти-әнисенең (законлы вәкиленең) шәхесен раслаучы документ | Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының территориаль органнары | законнар нигезендә |
| 3. | Укытучыга карата опека яисә попечительлекне гамәлгә ашыру хокукын раслый торган документ (укучы мәнфәгатьләрендә дәүләт хезмәте күрсәтүгә шартнамә төзүче һәм | опека һәм попечительлек органнары | опека һәм попечительлек органнары карары нигезендә |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | укучының опекуы яисә попечителе булган затлар өчен) | | |
| 4. | Укучының әти-әниләренең (законлы вәкилләренең) язмача гаризасы яки ризалыгы | укучының әти-әниләре (законлы вәкилләре) | укучы 18 яшькә җиткәнче (18 яшьне кертеп) |
| 5. | Бала үсеше тарихыннан өземтә (112/у формасы) | медицина оешмасы | укучы 18 яшькә җиткәнче |
| 6. | Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык | - | законнар нигезендә |
| Чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар өчен, шул исәптән чит илдә яшәүче ватандашлар өчен | | | |
| 1. | Укучының шәхесен раслый торган документ | чит ил дәүләтенең вәкаләтле органы яки Россия Федерациясенең вәкаләтле органы | законнар нигезендә |
| 2. | Укучы мәнфәгатьләрендә дәүләт хезмәте күрсәтү турында килешү төзүче укучының әти-әнисенең (законлы вәкиленең) шәхесен раслаучы документ | чит ил дәүләтенең вәкаләтле органы яки Россия Федерациясенең вәкаләтле органы | законнар нигезендә |
| 3. | Укытучыга карата опека яисә попечительлекне гамәлгә ашыру хокукын раслый торган документ (укучы мәнфәгатьләрендә дәүләт хезмәте күрсәтүгә шартнамә төзүче һәм укучының опекуы яисә попечителе булган затлар өчен) | опека һәм попечительлек органнары | опека һәм попечительлек органнары карары нигезендә |
| 4. | Укучының әти-әниләренең (законлы вәкилләренең) язмача гаризасы яки ризалыгы | укучының әти-әниләре (законлы вәкилләре) | укучы 18 яшькә җиткәнче (18 яшьне кертеп) |
| 5. | Бала үсеше тарихыннан өземтә | медицина оешмасы | укучы 18 яшькә җиткәнче |
| 6. | Туганлыкны яки баланың хокукларын законлы рәвештә тәкъдим итүне раслаучы документ | Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының территориаль органнары | законнар нигезендә |
| 7. | Укучының ата-анасының (законлы вәкиленең) Россия Федерациясендә булу хокукын раслаучы документ | Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының территориаль органнары | законнар нигезендә |
| 8. | Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык | - | законнар нигезендә |

## IV. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм шартларына таләпләр

4.1. Республика башкарма хакимият органнары гамәлгә куючы булып торган психология-педагогик, медицина һәм социаль ярдәм үзәкләрендә (алга таба – Үзәк) дәүләт хезмәте күрсәтелә.

4.2. Коррекцион-үстерү, компенсацияләү һәм логопедик дәресләрнең (алга таба – дәресләр) эчтәлеге һәм дәвамлылыгы һәр төгәл бер очракта укучыларның яшь үзенчәлекләренә һәм индивидуаль-психологик үзенчәлекләренә бәйле.

4.3. Педагог-психолог, логопед-укытучы, дефектолог-укытучы белән коррекцион-үстерү дәресләрен узу диагностик тикшерү үткәргәннән соң, белгеч тарафыннан билгеләнә.

4.4. Укучыларның шәхси үзенчәлекләрен диагностик тикшерү укучыларның соравы буенча, ә балигъ булмаган укучылар өчен – ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) соравы буенча үткәрелә. Укучыларның шәхси үзенчәлекләрен диагностик тикшерү психолог, педагог-психолог бәяләмәсе буенча, һәр очрашуга 45 минут вакыт биреп, ике – биш очрашу дәвамында башкарыла. Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура укучыларның журналда психологик тикшерүгә язылу датасы һәм вакытына туры килә. Процедура нәтиҗәсе булып психологик тикшерү беркетмәләре һәм язмача тәкъдимнәр белән бәяләмә, шул исәптән педагог-психолог, логопед-укытучы, дефектолог-укытучы белән коррекцион-үстерү дәресләрен узу тәкъдимнәре тора.

4.5. Укучыларның ата-аналары (законлы вәкилләре) дәүләт хезмәтен күрсәтү формасын сайлый алалар.

4.6. Дәүләт хезмәтен күрсәтү формалары:

индивидуаль дәресләр, дәресләрнең дәвамлылыгы укучының шәхси ихтыяҗларыннан чыгып 30 дан 45 минутка кадәр билгеләнә, индивидуаль программаларны гамәлгә ашыру вакыты дәүләт хезмәте күрсәтүче оешманың локаль акты һәм дәүләт хезмәте күрсәтү килешүе нигезендә бер айдан алты айга кадәр тәшкил итә (педагог-психолог, логопед-укытучы, дефектолог-укытучы бәяләмәләре буенча);

төркемле дәресләр, төркемнең тулылыгы 12 кешедән артмаска тиеш, бер дәреснең дәвамлылыгы 45 минут тәшкил итә, төркемле программаны гамәлгә ашыру вакыты дәүләт хезмәте күрсәтүче оешманың локаль акты һәм дәүләт хезмәте күрсәтү килешүе нигезендә бер айдан алты айга кадәр тәшкил итә (педагог-психолог, логопед-укытучы, дефектолог-укытучы бәяләмәләре буенча).

4.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып төгәл бер укучының үсешендә диагностик үзгәрешләр тора. Дәресләр үткәрү буенча мәгълүматлар эш төрләрен исәпләү журналына кертелә.

## V. Дәүләт хезмәтен матди-техник тәэмин итүгә таләпләр

5.1. Үзәктә санитар-эпидемиологик таләпләргә һәм нормаларга җавап бирә торган бүлмәләр һәм янәшәсендә территория каралган булырга тиеш. Биналар һәм бүлмәләр коммуналь-көнкүреш хезмәтләре, телефон элемтәсе белән тәэмин ителгән булырга тиеш.

Территория төзеклэндерелгэн һәм яшелләндерелгән булырга тиеш. Территориядә Үзәк белән функциональ бәйләнеше булмаган төзелмәләр һәм корылмалар урнаштыру рөхсәт ителми.

Үзәк территориясендә кирәк булган саен җыештыру үткәрелергә тиеш. Кышкы вакытта кирәк булган саен территорияне кардан чистарту үткәрелергә тиеш, территориягә ком сибү рөхсәт ителә. Химик реагентлар куллану рөхсәт ителми.

5.2. Үзәк бинасында түбәндәге бүлмәләр каралган булырга тиеш:

дәресләр үткәрү өчен белгечләр кабинетлары;

администрация кабинетлары;

методик кабинет;

белгечләр өчен хезмәт-көнкүреш бүлмәләре.

5.3. Методик кабинетта белгечнең эш өстәле, компьютер өстәле, оештыру техникасы өчен өстәл, ярдәмлекләр, документлар өчен шкафлар, шул исәптән документлар саклау өчен ачкыч белән бикләнә торган сейф яки шкаф булу күздә тотыла.

Логопед-укытучы кабинеты шулай ук укучыларның үсешендәге бозуларын төзәтү дәресләре үткәрү өчен диварда көзге (кимендә 1,5 – 0,5 м), төркемдәге балалар санына карап балалар өчен өстәл көзгеләре (9 х 12 см), көзге янында өстәмә яктырту (өстәл лампасы), фланелеграф, кәгазь сөлге белән җиһазландырыла.

5.4. Бүлмәләр укыту-күрсәтмә ярдәмлекләр, коррекция һәм тернәкләндерү техник чаралары, җыештыру техник чаралары урнаштыру өчен өстәмә урынны үз эченә алырга тиеш.

5.5. Бүлмәләрнең техник хәле санитар-эпидемиологик нормалар һәм кагыйдәләргә, янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләренә, хезмәт куркынычсызлыгына туры килергә тиеш, шулай ук бүлмәләр күрсәтелә торган дәүләт хезмәте сыйфатына тискәре йогынты ясый торган факторлардан (шул исәптән һава температурасының югары булуы, һава дымлылыгы, тузанлылык, пычрану, тавыш, вибрация) сакланган булырга тиеш.

5.6. Үзәкнең матди-техник җиһазлануы, шул исәптән оештыру-техник һәм программалы-методик тәэмин ителеше, оештыру техникасы (компьютер, принтер, ксерокс, сканер), видеоязмалар һәм слайдлар җыелмасы белән видео күрсәтү системасы, тавыш язмалары җыелмасы белән тавыш чыгару системасы; хуҗалык инвентары белән тәэмин итү һ.б. күздә тота.

5.7. Үзәкнең педагог-психолог, логопед-укытучы, дефектолог-укытучы кабинетын методик тәэмин итү кешенең психик тормышының барлык якларын колачлаган төрле юнәлештәге методикалар җыелмасын үз эченә ала: психик процесслар, халәтләр, шәхеснең юнәлеше, кыйммәтләр ориентирлары, интеллектуаль дәрәҗә, шәхесара үзара бәйләнеш үзенчәлекләре һәм тормыш эшчәнлегенең башка өлкәләре.

Методикалар җыелмасы тирән психологик анализ үткәрү һәм дөрес интерпретацияләү мөмкинлеген тәэмин итү өчен төрле яшь төркемнәре өчен методикаларны үз эченә алырга тиеш, шул исәптән актуаль хәлләрне теркәү һәм фаразлау төзү, "якын арадагы үсеш зонасын" билгеләү мөмкинлеге өчен төрле күрсәткечләрнең динамикасын комплексль рәвештә.

Методикалар индивидуаль һәм төркемле тикшерену өчен булырга тиеш.

Үзәк бары тик аттестацияләнгән психодиагностика методикаларын куллана.

5.8. Аларның юнәлешенә карап методикалар исемлеге түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

балаларның мәктәпкәчә белем бирү оешмасына психологик әзерлеген өйрәнү методикалары;

уен үсешен диагностикалау һәм өйрәнү методикалары;

балаларның мәктәптә укырга психологик әзерлеген диагностикалау һәм өйрәнү методикалары;

психик үсеш тоткарлыклары һәм интеллект бозылуларын аеру методикалары;

балалар, үсмерләр һәм өлкәннәрнең эмоциональ-ирекле өлкәсен өйрәнү һәм коррекцияләү методикалары;

балалар, үсмерләр һәм өлкәннәрнең шәхес өлкәсен өйрәнү методикалары;

гаилә мөнәсәбәтләрен диагностикалау методикалары;

төркемдә, оешманың педагогик коллективы белән балалар арасындагы мөнәсәбәтләрне диагностикалау һәм коррекцияләү методикалары;

балалар һәм үсмерләрнең танып белү процессларын үстерү методикалары;

тел үсешен тикшерү методикалары;

психокоррекцион эш методикалары;

психогимнастика, психологик бушану үткәрү өчен музыкаль язмалар белән аудиокассеталар.

билгеле бер белем бирү оешмасының ихтыяҗларына карап башка методикалар (укытучыларның профессионализм дәрәҗәсен өйрәнү методикалары, психокоррекция эшенең аудиоязмалары һ.б);

профессиональ диагностика һәм профориентация эшләре методикалары.

Үзәк өстәмә аттестацияләнгән методикаларны куллануны локаль акт белән раслый ала.

5.9. Методик чаралар түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

балалар һәм үсмерләрдә үсеш һәм тәртип бозуларын профилактикалау, диагностикалау һәм коррекцияләү өчен гамәли материаллар җыелмасы;

уенчыклар һәм өстәл уеннары җыелмасы (туплар, курчаклар, пирамидалар, кубиклар, лото, домино, мозаикалар, сюжетлы-рольле уеннар җыелмасы, битлекләр, музыка уен кораллары һ.б);

балалар иҗаты өчен материаллар җыелмасы (пластилин, буяулар, төсле карандашлар, фломастерлар, төсле кәгазь, җилем, картон, кайчы, кәгазь һ.б);

укучылар, ата-аналар (законлы вәкилләр), педагогик хезмәткәрләр өчен таратма материаллар.

5.10. Педагог-психолог, логопед-укытучы, дефектолог-укытучы китапханәсе түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

гомуми психология буенча әдәбият (сүзлекләрне дә кертеп);

балалар психологиясе буенча әдәбият;

педагогик психология буенча әдәбият;

диагностик әдәбият;

коррекцион-үстерү әдәбияты;

укучыларның ата-аналары (законлы вәкилләре) өчен әдәбият;

психологик хезмәтне оештыру буенча әдәбият;

хокукый мәсьәләләр буенча әдәбият;

периодик басмалар.

## VI. Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең куркынычсызлык таләпләре

6.1. Үзәк законнар нигезендә юридик зат буларак теркәлгән булырга тиеш.

6.2. Үзәкнең бүлмәләре «Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында техник регламент» 2008 елның 22 июлендәге 123-ФЗ номерлы федераль законда, федераль законнар белән расланган санитар-эпидемиологик кагыйдәләр һәм нормаларда күрсәтелгән таләпләргә туры килергә тиеш.

Укучылар өчен үлмәләрне подвалларда һәм цоколь катларында урнаштыру рөхсәт ителми.

6.3. Үзәк хезмәткәрләре кирәк булганда хезмәт алучыларга беренчел медицина-санитар ярдәм күрсәтәләр.

6.4. Үзәк табигый һәм ясалма яктырту чыганаклары белән җиһазландырылган булырга тиеш, бүлмәләрдәге яктырту дәрәҗәсе санитар таләпләргә туры килергә тиеш, бүлмәләрнең микроклиматы һәм һава мохите параметрлары нормаларын тәэмин итә торган җылылык һәм вентиляция системалары белән җиһазландырылган булырга тиеш.

6.5. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә кулланылган әйберләр һәм җиһазлар Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән санитар-эпидемиологик таләпләргә җавап бирергә тиеш. Күрсәтелгән бүлмәләрдә дәүләт хезмәте күрсәтү процессы белән бәйле булмаган җиһазлар булмаска тиеш.

6.6. Үзәк полицияне ашыгыч чакыру төймәсе белән җиһазландырылган булырга тиеш. Гадәттән тыш хәл килеп чыккан очракта Үзәк хезмәткәрләре укучыларны эвакуацияләү һәм коткаруны тәэмин итә. Гадәттән тыш хәл килеп чыкканнан башлап, аны бетерү яки эвакуацияләүгә кадәр укучыларны күзәтүсез калдыру тыела.

6.7. Үзәк түбәндәгеләр белән җиһазландырылган булырга тиеш:

автоматик янгын сигнализациясе;

янгын турында хәбәр итү системасы;

кирәкле янгын сүндерү чаралары;

шәхси саклану чаралары;

эвакуацияне оештыру өчен кирәкле чаралар.

6.8. Үзәктә:

күренеп торган урыннарда янгын чыккан очракта кешеләрне эвакуацияләү планнары (схемалары) эленгән;

хезмәткәрләрнең кешеләрне куркынычсыз һәм тиз эвакуацияләү буенча гамәлләрен билгеләүче инструкция бар;

кимендә ярты елга бер тапкыр Үзәкнең эвакуациядә катнашучы барлык хезмәткәрләре белән практик күнегүләр үткәрелә.

6.9. Үзәк Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә укучыларның, Үзәк хезмәткәрләренең хокуклары һәм ирекләре, укучыларның, Үзәк хезмәткәрләренең тормышы һәм сәламәтлеге, Үзәк уставы белән билгеләнгән функцияләрне үтәү өчен җаваплылык тота.

## VII. Дәүләт хезмәтен алучылар өчен аның мөмкинлеген тәэмин итүче таләпләр

7.1. Дәүләт хезмәтен алучыларны кабул итү күләме һәм структурасы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә дәүләт биреме белән билгеләнә.

7.2. Дәүләт хезмәтенә ихтыяҗ аны күрсәтүдән артып киткән очракта (ихтыяҗ ел дәвамында тәкъдимнән югары һәм дәүләт биременнән артмый) дәүләт хезмәтен күрсәтү мөмкинлегеннән өстенлекле рәвештә дәүләт хезмәтен күрсәтү чиратлылыгы журналда алдан язылуның хронологик тәртибе белән көйләнә.

7.3. Үзәк укучылар һәм укучыларның ата-аналары (законлы вәкилләре) дәүләт хезмәтен алуда һәм аңа ирешүдә төп ихтыяҗларын һәм аларның тормыш эшчәнлегенең төп чикләүләрен исәпкә алып, киртәсез керү мөмкинлеген тәэмин итү өчен транспорт инфраструктурасы уңайлы булган урыннарда урнашырга тиеш.

7.4. Иң уңайлы эш һәм ял режимын булдыру максатыннан Үзәк хезмәтләренең расписаниесе укучыларның яшь үзенчәлекләрен һәм санитар-гигиеник нормаларны исәпкә алып төзелә, шул ук вакытта Үзәктә дәүләт хезмәтен күрсәтү иртәнге 8.00 сәгатьтән иртәрәк башланмаска, ә кичке 20.00 сәгатьтән соңга калмаска тиеш.

Үзәкнең эш режимы устав һәм Үзәкнең башка локаль актлары белән көйләнә.

7.5. Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү законнар нигезендә беренчел тәртиптә башкарыла.

Инвалидларга, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затларга дәүләт хезмәте күрсәткәндә хезмәтләр күрсәтүнең һәркем өчен ачык булуын һәм хезмәтләр күрсәтүне тәэмин итүне яисә сурдотәрҗемәчеләр, тифлосурдотәрҗемәчеләр Үзәккә керү мөмкинлеген тәэмин итүне үз эченә ала торган дәүләт хезмәтен күрсәтүнең махсус шартларын оештыру тәэмин ителә.

Хезмәт күрсәтү мөмкинлеге Үзәк хезмәткәрләре һәм баланы озатып йөрүче өлкән кеше ярдәмендә тәэмин ителә.

7.6. Дәүләт хезмәте күрсәтүче оешмалар Татарстан Республикасы территориясендә транспорт белән яхшы тәэмин ителгән, дәүләт хезмәте алучылар өчен уңайлы урыннарда урнашкан булырга тиеш.

## VIII. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең кадрлар белән тәэмин ителү дәрәҗәсенә таләпләр

8.1. Үзәк штат расписаниесенә туры килгән квалификацияле белгечләр белән комплектланырга тиеш. Үзәкне белгечләр белән комплектлау тәртибе гамәлгә куючы тарафыннан расланган штат саны кысаларында билгеләнә.

8.2. Педагогик эшчәнлеккә педагог-психологның һөнәри стандарты белән билгеләнгән тәртиптә билгеләнгән белем дәрәҗәсенә ия булган затлар гына кертелә.

8.3. Белгечләрнең квалификациясен югары дәрәҗәдә тоту өчен даими (өч елга бер тапкырдан да ким булмаган) яңадан әзерлек һәм квалификация күтәрү курсларында укулар үткәрелергә тиеш. Һәр категория белгечләренең аларның хокукларын һәм бурычларын билгеләүче вазыйфа инструкцияләре булырга тиеш.

8.4. Тиешле квалификация һәм профессионализм белән беррәттән, Үзәкнең барлык белгечләре югары әхлакый сыйфатларга, җаваплылык хисенә ия булырга тиеш.

Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытында Үзәк белгечләре укучыларга һәм аларның ата-аналарына (законлы вәкилләренә) максималь әдәплелек, игътибарлылык, сабырлык, алдан күрүчәнлек, түземлелек күрсәтергә тиеш.

8.5. Үзәк белгечләре эшкә кергәндә мәҗбүри медицина тикшерүләре һәм билгеләнгән тәртиптә периодик медицина тикшерүләре үтәргә тиеш. Медицина

тикшерүләреннән, һөнәри һәм гигиена әзерлегеннән качучы, медицина тикшерүләре һәм һөнәри гигиена әзерлеге нәтиҗәләре белән билгеләнгән үрнәктәге шәхси медицина китабы булмаган белгечләр эшкә кертелми.

Үзәк белгечләре шәхси гигиена кагыйдәләрен үтәргә тиеш: эшкә чиста кием һәм аяк киемендә килергә.

Йогышлы авырулары булуда шикләнелгән Үзәк белгечләре эшкә кертелми яки шунда ук эштән читләштерелә.

8.6. Педагогик эшчәнлеккә түбәндәге затлар кертелми:

законлы көченә кергән суд карары белән педагогик эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм ителгәннәр;

шәхеснең гомеренә һәм сәламәтлегенә, ирегенә, намусына һәм абруена каршы, җенси кагылгысызлык һәм шәхеснең җенси иреге, гаиләгә һәм балигъ булмаганнарга, халыкның һәм иҗтимагый әхлакның сәламәтлегенә, дәүләтнең конституциячел корылышы һәм иминлеге нигезләренә, тынычлык һәм кешелек иминлегенә каршы, шулай ук иҗтимагый иминлеккә каршы җинаятьләр өчен (психиатрия ярдәмен стационар шартларында күрсәтә торган медицина оешмасына законсыз урнаштырудан һәм яла ягудан тыш) һөкем ителгән яисә элегрәк хөкем ителгән, җинаять эзәрлекләвенә дучар булган затлар (реабилитацияләү нигезләре буенча җинаять эзәрлекләве туктатылган затлардан тыш), Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 331 статьясындагы өченче өлешендә каралган һәм әлеге пунктның җиденче абзацында күрсәтелгән очраклардан тыш;

бүтән аңлы рәвештә кылынган авыр яки үтә авыр җинаятьләр өчен кире алынмаган яисә юкка чыгарылмаган хөкем ителүе булган, әмма Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 331 статьясының өченче абзацында һәм әлеге пунктның өченче абзацында күрсәтелмәгән кешеләр;

федераль закон белән билгеләнгән тәртиптә эшкә сәләтсез дип танылган;

сәламәтлек саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан расланган исемлек белән каралган авырулары булган;

чит ил агентлары дип танылган.

Россия Федерациясенең Трудовой кодексының 331 статьясының икенче өлешенең өченче абзацында һәм әлеге пунктның өченче абзацында күрсәтелгән затлар, тормыш һәм сәламәтлеккә, ирекккә, намус һәм шәхеснең дәрәҗәсенә каршы (медицина оешмасына законсыз госпитализацияләү һәм яла ягу искәрмәләреннән тыш), гаилә һәм балигъ булмаганнар, халык сәламәтлеге һәм җәмәгать әхлагы, конституцион төзелеш нигезләре һәм дәүләт иминлеге, дөнья һәм кешелек иминлеге, шулай ук җәмәгать иминлегенә каршы җиңел һәм уртача авырлыктагы җинаятьләр өчен хөкем ителгән һәм әлеге җинаятьләрне кылуда гаепләү буенча җинаять эзәрлекләве акланмый торган нигезләрдә туктатылган затлар, балигъ булмаганнарны тәрбияләү, үстерү, аларның ялы һәм сәламәтләндерүен оештыру, медицина белән тәэмин итү, социаль яклау һәм социаль хезмәт күрсәтү, балалар-үсмерләр спорты, Культура һәм сәнгать өлкәсендә балигъ булмаганнар катнашында эшчәнлеккә Республиканың балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең тиешле эшчәнлек төренә рөхсәте булганда җибәрелергә мөмкин.

## IX. Дәүләт хезмәтен алу өчен мөрәҗәгать иткәндә һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү барышында дәүләт хезмәте алучыларны мәгълүмати тәэмин итү таләпләре

9.1. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат Россия Федерациясенең «Кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 7 февралендәге 300-1 номерлы законы таләпләренә туры килергә тиеш.

9.2. Үзәкнең эшчәнлеге, дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе һәм кагыйдәләре, дәүләт хезмәтенең күләме, дәүләт биремен үтәү турында хисап, дәүләт хезмәте стандарты турында мәгълүмат укучының ата-анасына (законлы вәкиленә), укучыга (15 яшькә җиткән) карарлык булырга тиеш.

9.3. Үзәк укучыларга, аларның ата-аналарына (законлы вәкилләренә) үзенең исемен һәм урнашу урынын җиткерергә тиеш. Әлеге мәгълүмат Россия Федерациясе законнары белән каралган һәм халыкка аның алырлык булуын тәэмин итүче теләсә кайсы ысул белән тәкъдим ителергә тиеш. Укучыларны, аларның ата-аналарын (законлы вәкилләрен) мәгълүмат белән тәэмин итү түбәндәге ысуллар белән башкарыла:

Үзәкне гамәлгә куючының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә массакүләм мәгълүмат чараларында әлеге Стандартны урнаштыру;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Үзәкнең рәсми сайтында, Үзәкне гамәлгә куючының рәсми сайтында Үзәкнең исеме һәм урнашу урыны, Үзәкнең эшчәнлеге (устав), күрсәтелә торган дәүләт хезмәтенең (дәүләт биреме) күләмнәре, дәүләт биремен үтәү турында хисаплар, дәүләт хезмәте стандарты турында мәгълүмат урнаштыру.

Мәгълүмати озату массакүләм мәгълүмат чараларында тематик басмалар хисабына тәэмин ителергә мөмкин.

9.4. Укучылар, аларның ата-аналары (законлы вәкилләре) башкарыла торган дәүләт хезмәте турында кирәкле һәм дөрес мәгълүмат таләп итәргә хокуклы.

9.5. Үзәк укучыларга, аларның ата-аналарына (законлы вәкилләренә) вакытында дәүләт хезмәте турында дөрес мәгълүмат бирергә, дәүләт хезмәтен алу кагыйдәләре һәм шартлары белән таныштырырга бурычлы. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат составына түбәндәгеләр керергә тиеш:

әлеге Стандарт;

дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары турында мәгълүмат;

укучыларның дәүләт хезмәте сыйфатына йогынты ясау мөмкинлеге турында мәгълүмат;

Үзәк белгечләре белән укучыларның аралашу чаралары турында мәгълүмат;

укучылар тарафыннан дәүләт хезмәте сыйфатын бәяләү мөмкинлеге турында мәгълүмат;

дәүләт хезмәтләрен нәтиҗәле һәм куркынычсыз күрсәтү кагыйдәләре һәм шартлары.

9.6. Үзәкнең эшчәнлеге, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм кагыйдәләре турында мәгълүмат кирәк булган саен, әмма кимендә елга ике тапкыр яңартылырга (актуальләштерелергә) тиеш.

## X. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

10.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге:

укучының хәзерге Стандартның 1.1 пунктында китерелгән дәүләт хезмәте алучылар категориясе характеристикаларына туры килмәве;

дәүләт хезмәтен алу өчен каршылыклар булу:

интеллект бозылуларының уртача һәм авыр дәрәҗәсе;

күрү һәм ишетү бозылуларының катлаулы кушылмасы (сукырлык һәм саңгыраулык);

ачык клиник симптоматика белән психик авырулар;

алкоголь яки наркотик исереклеге хәле;

Үзәк белән укучының ата-анасы (законлы вәкиле) арасында төзелгән килешүне өзү.

10.2. Килешүне өзү нигезләр килешү текстында булырга тиеш. Бер якның инициативасы белән килешүне өзү нигезләре:

килешү шартларын мөһим һәм (яки) системалы бозу;

Үзәкнең гамәлгә кую документларында каралган эчке кагыйдәләрне бозу.

## XI. Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе тасвирламасы

11.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү сыйфаты индикаторлары түбәндәге таблицада китерелгән:

| Күрсәткеч исеме | Үлчәү берәмлеге | Исәпләү формуласы | Мәгълүмат чыганагы | Индикаторның чик күрсәткече | Авырлык коэффиценты |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1. Дәүләт хезмәтенең сыйфаты һәм мөмкинлеге белән канәгать булган укучылар өлеше | процент | $\frac{О_к + О_д}{2 \times О_{общ}} \times 100\%$, монда: $О_к$ – дәүләт хезмәтләре сыйфаты белән канәгать булган сораштырылганнар саны; $О_д$ – дәүләт хезмәтләре мөмкинлеге белән канәгать булган сораштырылганнар саны; $О_{гом}$ – сораштырыл- | укучыларны сораштыру нәтиҗәләре буенча | 90 | 9 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | | ганнарның гомуми саны | | | |
| 2. Укучыларның нигезле шикаятьләре өлеше | процент | $\frac{Ж_о}{Ж} \times 100\%$,<br><br>монда:<br>$Ж_о$ – хисап чорында кергән укучыларның нигезле шикаятьләре саны;<br>Ж – хисап чорында кергән укучыларның гомуми шикаятьләре саны | укучыларның шикаятьләрен һәм алар буенча кабул ителгән чаралар турында мәгълүматны анализлау | 0 | 9 |
| 3. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытында санитар-эпидемиологик режим бозуларның булуы | берәмлек | контроль-күзәтчелек органнарының күрсәтмәләрендә теркәлгән бозулар саны | мониторинг нәтиҗәләре буенча билгеләнә | 0 | 8 |
| 4. Профильле һөнәри белемгә ия белгечләр өлеше | процент | $\frac{П_о}{О_{кс}} \times 100\%$,<br><br>монда:<br>$П_о$ – профильле һөнәри белемгә ия белгечләр өлеше;<br>$О_{кс}$ – квалификацияле белгечләрнең гомуми саны | мониторинг нәтиҗәләре буенча билгеләнә | 100 | 6 |
| 5. Коррекцион-үстерү һәм компенсацияләүче дәресләр алган укучыларның гомуми санында коррекцион-үстерү һәм компенсацияләүче дәресләр алганнан соң уңай нәтиҗәләргә | процент | $\frac{А}{В} \times 100\%$,<br>монда:<br>А – коррекцион-үстерү һәм компенсацияләүче дәресләр алганнан соң уңай нәтиҗәләргә ирешкән укучылар саны;<br>В – коррекцион-үстерү һәм ком- | мониторинг нәтиҗәләре буенча билгеләнә | 85 | 8 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| ирешкән укучылар өлеше | | пенсацияләүче дәресләр алган укучыларның гомуми саны | | | |
| 6. Логопедик ярдәм алган укучыларның гомуми санында логопедик ярдәм алганнан соң уңай нәтиҗәләргә ирешкән укучылар өлеше | процент | $\frac{A}{B} \times 100\%$, <br><br>монда:<br>А – логопедик ярдәм алганнан соң уңай нәтиҗәләргә ирешкән укучылар саны;<br>В – логопедик ярдәм алган укучыларның гомуми саны | мониторинг нәтиҗәләре буенча билгеләнә | 85 | 8 |

## XII. Әлеге Стандартны үтәмәүгә карата шикаятьләрне бирү, теркәү һәм карау тәртибе

12.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибен бозу турында шикаять (алга таба – шикаять) язмача рәвештә кәгазьдә, электрон формада Үзәккә бирелә. Үзәк җитәкчесенең карарларыны һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр Үзәкнең гамәлгә куючылары тарафыннан бирелә.

12.2. Шикаятьне укучыларның ата-аналары (законлы вәкилләре), балигъ булган укучылар бирә ала.

12.3. Үзәкнең, Үзәк җитәкчесенең, Үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять почта аша, «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәре, Үзәкнең рәсми сайты, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы (www.gosuslugi.ru) яки Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы (uslugi.tatarstan.ru), Үзәкне гамәлгә куючыларныың рәсми сайты аша җибәрелергә мөмкин, шулай ук шәхси кабул итү вакытында кабул ителергә мөмкин.

Шикаятьне теркәү Үзәкнең эш алып бару кагыйдәләренә ярашлы рәвештә шикаять килгән көннән өч календарь көннән дә соңга калмыйча башкарыла.

12.4. Шикаять законнар белән билгеләнгән таләпләргә туры килергә тиеш.

12.5. Шикаять, шикаятьләрне карау вәкаләтләренә ия булган вазыйфаи зат тарафыннан, теркәлгән көннән башлап 15 эш көне эчендә каралырга тиеш, Үзәкнең, Үзәкнең вазыйфаи затының дәүләт хезмәтен алучыдан документлар кабул итүдә баш тартуына карата шикаять белдергән очракта йә җибәрелгән басма хаталарны төзәтүдә яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогы бозылуга карата шикаять белдергән очракта - аны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә.

12.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча карар кабул ителә һәм аны кабул иткән көннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча, дәүләт хезмәте алучыга язмача

һәм дәүләт хезмәте алучының теләге буенча электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

12.7. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип табылган очракта, дәүләт хезмәте алучыга җавапта Үзәк тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүдә ачыкланган бозуларны кичекмәстән бетерү максатында башкарылган гамәлләр һәм дәүләт хезмәтен алу максатында дәүләт хезмәте алучы тарафыннан башкарылырга тиешле алдагы гамәлләр турында мәгълүмат бирелә.

12.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип табылган очракта, дәүләт хезмәтен алучыга кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга карата шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

12.9. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү буенча вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны, кичекмәстән, прокуратура органнарына җибәрә.

12.10. Дәүләт хезмәтен алучылар дәүләт хезмәтен күрсәтү белән бәйле карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауга) Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә шикаять бирә ала.

## XIII. Дәүләт хакимияте органнары тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе

13.1. Дәүләт хакимияте органнары ягыннан дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре күрсәтә торган дәүләт хезмәтләре сыйфатының билгеләнгән стандартларына туры килүен бәяләүне уздыру тәртибе турында» 2009 ел, 30 июнь, 446 нчы карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

## XIV. Дәүләт хезмәтен түләүле яки бушлай күрсәтү турында мәгълүмат

14.1. Дәүләт хезмәте тиешле елга Үзәккә каралган дәүләт йөкләмәсе чаралары чикләрендә бушлай күрсәтелә.

---